ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ _______________ КАРАР _______________

с. Верхний Услон

Инженер челтәрләре һәм коммуникацияләр трассалары схемасын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

Югары Ослан муниципаль районы хакимияте органнарының физик һәм юридик затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү буенча эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген һәм сыйфатын күтәрү максатларында һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Уставы һәм тышкы төзекләндерү кагыйдәләре белән расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен исәпкә алып, Югары Ослан муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Инженер челтәрләре һәм коммуникацияләр трассалары схемасын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын расларга.
2. «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2014 елның 17 апрелендәге 517 номерлы карарының 1.1.10 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгына әлеге карар белән расланган муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын үтәүне тәэмин итәргә.
4. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Социаль-икътисадый үсеш буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Л.С. Хәкимҗанов

Әзерләде һәм бастырды:
А.Д.Сагдеева
2 экз.